КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 25 июль г.Казань № 593

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы бюджет учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы бюджет учреждениеләре булып торган Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары тарафыннан бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2011 ел, 6 июнь, 449 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 1 март, 143 нче; 2013 ел, 24 май, 348 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 51 нче; 2014 ел, 11 август, 583 нче; 2015 ел, 18 май, 353 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 645 нче; 2016 ел, 26 октябрь, 780 нче; 2017 ел, 14 апрель, 228 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1041 нче; 2019 ел, 26 ноябрь,

1080 нче; 2020 ел, 3 февраль, 69 нчы; 2020 ел, 14 апрель, 281 нче; 2020 ел, 23 июнь, 521 нче; 2020 ел, 4 ноябрь, 991 нче; 2021 ел, 25 февраль, 98 нче; 2021 ел, 20 октябрь, 989 нчы; 2023 ел, 22 июль, 879 нчы; 2023 ел, 10 август, 965 нче; 2023 ел, 25 ноябрь, 1517 нче; 2024 ел, 7 май, 308 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) алар карамагындагы казна учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәренең баш администраторлары бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләренә, түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пунктча өстәп, үзгәреш кертергә:

«$2^1$. Бюджет керемнәренең баш администраторлары, түбәндәгеләрне тәэмин итеп, дебиторлык бурычы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрә:

дебиторлык бурычлары күләмнәре турында хисаплылыкны һәм исәпкә алу мәгълүматларын аларга инвентаризация ясау һәм федераль стандартларда каралган нигезләмәләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән карарлар кабул итү юлы белән актуальләштерү;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, дебиторлык бурычы динамикасын мониторинглау һәм ведомство буйсынуындагы керемнәр администраторларына беркетелгән керемнәрне администрацияләү буенча вәкаләтләрнең үтәлешен бәяләү;

шикаять-дәгъва эшенең сыйфатын яхшырту.

Бюджет керемнәренең баш администраторлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, ел өчен – хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр дебиторлык бурычы белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру буенча күрелгән чаралар турында, шул исәптән аларга беркетелгән Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары керемнәре чыганаклары буенча бурычларны түләтү чаралары турында (бурычлыларга җибәрелгән шикаятьләр (таләпләр) һәм суд органнарына дәгъвалар санын һәм суммасын, шикаять-дәгъва эше нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы бюджетына һәм (яки) җирле бюджетларга кергән керемнәр суммасын кертеп) мәгълүмат бирелгән хисап тапшыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин